КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.03.2025 № 100-П

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2019 елның 22 нче октябрендәге «Казан шәһәрендә урнашкан региональ әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары территорияләре чикләрен раслау турында»гы 126-П номерлы боерыгының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы Федераль законы, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2024 елның 5 нче декабрендәге уңай бәяләмәсе нигезендә боерам:

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2019 нчы елның 22 нче октябрендәге «Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары территориясе чикләрен раслау турында"гы 126-П номерлы боерыгының 1 нче кушымтасындагы 25 нче пунктына (Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2020 нче елның 5 нче октябрендәге 213-П номерлы, 2021 нче елның 5 нче февралендәге 24-П номерлы, 2021 нче елның 8 нче июнендәге 124-П номерлы, 2022 нче елның 10 нчы февралендәге 16-П номерлы, 2022 нче елның 9 нчы мартындагы 31-П номерлы, 2022 нче елның 3 нче августындагы 229-п номерлы, 2022 нче елның 25 нче октябрендәге 392-п номерлы, 2023 нче елның 5 нче маендагы 164-п номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан "Язучы Фәтхи Бурнаш (1923-1940 еллар) һәм шагыйрь Фатих Кәрим (1931-1941 еллар) яшәгән йорт. Сәүдәгәр Чернояровның керем йорты–пассажы", 1923-1940 еллар, 1931-1941 еллар, XX гасыр башы төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасын (схемасын) түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

«Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан "Язучы Фәтхи Бурнаш (1923-1940 еллар) һәм шагыйрь Фатих Кәрим (1931-1941 еллар) яшәгән йорт. Сәүдәгәр Чернояровның керем йорты–пассажы", 1923-1940 еллар, 1931-1941 еллар, XX гасыр башы төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең картасы (схемасы)




Масштабы 1:1000

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | - мәдәни мирас объекты |
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләре |
| **1** | - объект территориясе чикләренең характерлы ноктасын билгеләү |
| | - БДКМР белешмәләре буенча җир кишәрлекләренең кадастр чикләре |
| 16:50:010305 | - кадастр кварталының номеры |

».

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин